| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.05.2018 Казан шәһәре № под-819/18

«Татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм» гранты турында

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларының татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләре әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларын ачыклау һәм ярдәм итү, шулай ук, татар теленә өйрәтү буенча иң яхшы педагогик тәҗрибәне тарату максатыннан б о е р а м:

1. «Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына татар теле буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне әзерләгән өчен ярдәм» грантын гамәлгә куярга (алга таба-грант).

2.Грант турындагы Положениене расларга.

3. Милли мәгариф идарәсенә (Л. М. Әхмәтҗанова), Грант турында Положение нигезендә, 2018 елның 1 июленнән 15 июленә кадәр Грант алуга конкурс сайлап алуны оештырырга һәм уздырырга.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә, (Г. К. Мөхәммәдкәримова) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә, Грант алу өчен конкурста җиңүчеләргә Грантлар бирүгә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә акча күчерү эшен оештырырга.

5. Милли мәгариф бүлегенә (И. Халиков) өч көнлек срокта. әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә тапшырырга.

6. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7.Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары И. Г. Һадиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары – министр Р.Т.Бурганов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
10.05. 2018 № под-819/18
боерыгы белән

«Татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм» гранты турында
Положение

1. Гомуми положениеләр

1.1.Әлеге Положение “Татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм” грантын алуга сайлап алу конкурсын оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2.Грант Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела (алга таба — министрлык).

1.3.Грантның максаты: Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының, татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләгән, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын ачыклау һәм бүләкләү.

1.4.Грантта катнашучылар - Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Министрлык.

Грантка дәгъва кылучы - Грант турындагы Положениенең 2.6 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм нигезләмә нигезендә Грант алуга конкурс узарга әзер физик зат.

Грант алучы - төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында эшләүче һәм Грант алуга Конкурс узган, әлеге Положениедә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган физик зат.

Грант булып бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тора:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, 8-11 сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне әзерләгән өчен,

115000 (йөз унбиш мең) сум күләмендә акчалата түләү түбәндәге категорияләр буенча билгеләнә:

татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең 8 нче сыйныф укучылары арасында татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең 9 нчы сыйныф укучылары арасында татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең 10 нчы сыйныф укучылары арасында татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең 11 нче сыйныф укучылары арасында татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәренең 8 нче сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәренең 9 нчы сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәренең 10 нчы сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәренең 11 нче сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең 8 нче сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең 9 нчы сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең 10 нчы сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең 1 нче сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчесе;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиадада Гран-при иясе.

1.5.Грант шәхси һәм өченче физик затларга тапшырыла алмый.

## 2. Конкурста катнашу өчен гаризалар бирү

2.1.Грантта катнашу өчен дәгъва кылучылар сыйфатында. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының түбәндәге таләпләргә туры килә торган, педагогик хезмәткәрләре дәгъва итә ала:

төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү буенча белем бирү программаларын тормышка ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 нче сыйныф укучылары арасыннан Татар теле буенча Халыкара олимпиадада җиңүчене әзерләүне раслый торган документлар булу.

2.2.Грант алуга Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.3.Грант бирүче, гаризалар тапшыру башланырга 10 көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, боерык урнаштыру юлы белән, Конкурс үткәрү турында игълан итә.

2.4.Грантка дәгъва кылучы, агымдагы елның 30 июненнән дә соңга калмыйча. башкарма комитет идарәсенең муниципаль органы (бүлеге) җитәкчесе һәм мәгариф оешмасы җитәкчесе белән килештерелгән гариза, әлеге Положениенең 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар пакетын «Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне әзерләгән өчен ярдәм " грантын оештыру комитетына кәгазь һәм электрон вариантта: 420011, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт, каб. 225 (9-00 дән 18-00 гә кадәр, төшке аш 13-00 дән 13-45 кә кадәр; шимбә, якшәмбе-ял көннәре) адресы буенча тапшырырга тиеш.

2.5.Гариза агымдагы елның 30 июненнән дә соңга калып бирелгән очракта, Грантка дәгъва кылучы Конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.6.Конкурста катнашу өчен оешма җитәкчесе имзасы белән түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

конкурста катнашу нияте турында язмача мөрәҗәгатьне үз эченә алган гариза, шулай ук документлар (1 кушымта):

Федераль законнар нигезендә, педагогик хезмәткәр педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасына белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бирелгән лицензия күчермәсе;

Грантка дәгъва кылучының педагогик белем бирү оешмасы хезмәткәре булуын раслаучы белешмә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларының 8-11 нче сыйныф укучылары арасыннан татар теле буенча Халыкара олимпиадада җиңүчесе булуын раслаучы документлар.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1.Грантка дәгъва кылучылар арасында Конкурс, Грантка дәгъва кылучылар тәкъдим иткән документларның, әлеге Положениенең 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәүгә экспертиза уздыру юлы белән үткәрелә.

3.2.Конкурс материалларын бәяләү өчен, комиссия рәисе һәм 9 кешедән торган комиссия әгъзалары составында, Республика конкурс комиссиясе төзелә.

3.3.Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.4.Конкурста катнашкан педагоглар эшли торган мәгариф оешмалары җитәкчеләре Республика конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый.

3.5.Республика конкурс комиссиясе утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм алар, составының яртысыннан артыгы катнашкан очракта гына, тулы хокуклы булып санала.

3.6.Республика конкурс комиссиясе, агымдагы елның 15 июленә кадәр, бирелгән гаризаларны карый, экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәләрен рәсмиләштерә (тапшырылган документларның әлеге Положениенең 2.6 пункты таләпләренә туры килүен билгели).

3.7.Грантка дәгъва кылучылар тәкъдим иткән документларны карау нәтиҗәләре буенча, Республика конкурс комиссиясе, аларның әлеге Положениенең 2.6 пункты таләпләренә туры килүе - килмәве турында карар кабул итә.

3.8. Грантка дәгъва кылучылар арасында конкурс нәтиҗәләре Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларының татар теле буенча Халыкара олимиада җиңүчесе булган 8 – 11 сыйныф укучыларының саны нигезендә билгеләнә.

Конкурс нәтиҗәләре буенча, грант суммасын күрсәтеп, грант алучылар исемлеге төзелә.

3.9.Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, конкурс үткәрү процедуралары бозылганда, конкурста катнашучы Республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, грантка дәгъва кылучылар конкурсы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән ун көнлек срокта, Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә ирекле формада бирелә.

3.10. Республика Конкурс комиссиясе карары, комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Республика конкурс комиссиясенең тавышы хәлиткеч хокукына ия була.

Апелляцияне карау нэтиҗәсендә, Республика конкурс комиссиясе, түбәндә күрсәтелгән ике карарның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагарга һәм игълан ителгән карарны үз көчендә калдырырга:

апелляцияне канәгатьләндерергә.

3.11. Апелляцияне карау нигезендә Республика конкурс комиссиясе тарафыннан протокол төзелә, рәис һәм утырышта катнашкан башка комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

3.12. Республика комиссиянең карарлары, гамәлләренә Россия законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

3.13. Сайлап алу нәтиҗәләре, карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә, министрлыкның официаль сайтында: Программы и проекты разделында, Гранты учителям “Поддержка учителю татарского языка и литературы за подготовку победителей Международной олимпиады по татарскому языку” подразделында урнаштырыла.

3.14. Грант алучылар исемлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.15. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында җиңүчеләр әзерләүдә катнашу турында грантка, дәгъва кылучаларның дөреслеккә туры килмәгән, яисә ялган мәгълүматлар бирүе ачыкланса, грант бирү турында карар кабул ителми

## 4. Конкурсны финанслау

Грант бирү максатларында субсидияләр бирү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

Кушымта
“Татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм” гранты турында Положениегә

РАСЛЫЙМ

______________________________

Муниципаль берәмлек исеме

Башкарма комитет Идарәсенең муниципаль органы (бүлеге) җитәкчесе__________________ФИО

“_____” _________20___ел

РАСЛЫЙМ

________________________________

Муниципаль берәмлек исеме

Белем бирү оешмасы җитәкчесе

________________________ФИО

“___”____________20_____ел

Конкурста катнашу өчен
Гариза

| Грантка дәгъва кылучының ФИО | Грантка дәгъва кылучын педагогик хезмәт алып бара торган белем бирү оешмасы җитәкчесенң ФИО | Белем бирү оешмасының юридик адресы, тетефон, электрон адрес | Татарстан Республикасында теркәлгән белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасыннан Татар теле буенча Халыкара олимпиада җиңүчеләрен әзерләүдә катнашу нәтиҗәләрен раслаучы документлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| | | | |

Кушымтада (Положениеның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар) билтәр санын күрсәтелә

*Гариза һәм документлар тегелгән, номерланган һәм белем бирү оешмасы җитәкчесе печате белән беркетелгән*

*Күрсәтелгән адрес буенча электрон һәм кәгазь вариантта, ябыштырылган конвертта тапшырыла*